ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 182-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.А. Чубаров, Р.Р. Фазылов тарафыннан кертелгән «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 182-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 8 июне
№ 643-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.А. Чубаров һәм Р.Р. Фазылов
тарафыннан кертелә

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның өченче өлешендә «янгын чыгу куркынычы һәм кешеләрнең иминлегенә зыян китерү куркынычы» сүзләрен «Федераль законның 1 статьясындагы утыз сигезенче яисә утыз тугызынчы абзацында күрсәтелгән куркыныч» сүзләренә алмаштырырга;

2) 19 статьяның җиденче өлешендәге сигезенче абзацында «оешмалар хезмәткәрләренең һәм аларның территорияләрендәге башка гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян килү куркынычы» сүзләрен «оешмалар хезмәткәрләренә һәм аларның территорияләрендәге башка гражданнарга Федераль законның 1 статьясындагы утыз сигезенче яисә утыз тугызынчы абзацында күрсәтелгән куркыныч» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы норматив хокукый базасын федераль законнардагы үзгәрешләр нигезендә үстерү максатларында эшләнде.

2026 елның 25 апрелендәге 110-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә ведомстводан тыш янгыннан саклану (12 статья) һәм янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару тәртибе (22 статья) турында нигезләмәләр төгәлләштерелә.

Шуңа бәйле рәвештә, «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының «Ведомство янгыннан саклану» 14 статьясының һәм «Янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару» 19 статьясының шундый ук нигезләмәләре югарыда әйтелгән Федераль законга туры китерелә.

Закон проекты ике статьядан тора. Закон проектының 2 статьясында законның үз көченә керү вакыты аның рәсми басылып чыккан көненнән дип карала.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башка законнар кабул итүне таләп итми.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар бүлеп бирүне таләп итми.